## Генерал якташыбыз

**/Чал тарихта эзле без/**

8 нче май көнне Такталы авылына Бөек Ватан сугышы истәлегенә яңадан торгызылган һәйкәл ачылышына бардык. Һәйкәлнең мәрмәр такталарына **генерал-майор Сәетгәрәй Гайфетдиновның** да исеме уелып язылган иде. Безнең төбәкнең иң күренекле вәкилләреннән саналырлык бу шәхес Такталы авылы халкына яхшы таныш булса да, башкалар аның турында белми диярлек. Шуңа күрә, гәзитебезнең бу санында Сәетгәрәй генерал турында мәкалә бирергә булдык.



Сәетгәрәй Гайфетдин улы 1900 нче елның 15 нче апрелендә Такталы авылында, ярлы игенче гаиләсендә дөньяга килә. 1915 нче елда Оренбург якларына китеп, хезмәт юлын башлап җибәрә. Октябрь революциясе булуга ук, 1917 нче елның ноябреннән Кызыл Гвардиягә язылуы Сәетгәрәйнең алдагы тормыш юлын билгели. Егетнең хәрби эшкә сәләте шул елларда ук ачыла. 1918 нче елда ул Оренбург мөселман комиссариатында инструктор, аерым Татар батальонында пулеметчы, ә 1919 нче елның башыннан 1 нче Оренбург мөселман полкында пулеметчылар взводы командиры итеп билгеләнә. Гражданнар сугышын Төркестан укчы дивизиясендә рота командиры буларак тәгәлли.

1920 нче еллар дәвамында Сәетгәрәй Гайфетдинов төрле гаскәрләрдә урта буын командир вазифасында хезмәт итә. 1932-1936 нчы елларда Мәскәүдә М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академиядә белем ала. Аны тәмамлаганнан соң Ерак Көнчыгыштагы 12 нче укчы дивизиясенә штаб начальнигы итеп җибәрелә. 1938 нче елның җәендә бер-бер артлы шушы дивизия составындагы 34 нче укчы полк командиры һәм Благовещенск укрепрайоны коменданты итеп билгеләнә. Шул ук елны ул беренче сугышчан бүләкләрен – “Кызыл Байрак” орденын һәм “Кызыл Армиянең XX еллыгы” истәлек медален ала. 1940 нчы елның маенда майор Гайфетдинов хезмәт иткән дивизия Ташкент шәһәренә күчерелә һәм ул анда В.И.Ленин исемендәге хәрби-сәяси академиядә укыту эшенә керешә.

Бөек Ватан сугышын Сәетгәрәй Гайфетдинов подполковник дәрәҗәсендә һәм 245 нче укчы дивизиянең штаб начальнигы вазифасында каршылый. Бу дивизия Төньяк-Көнбатыш фронтта сугышлар алып бара. 1941 нче елның декабрендә Себер хәрби округына җибәрелеп, Новосибирск шәһәрендә 235 нче укчы дивизияне оештыра. 1942 нче елның июленнән 1943 нче елның апреленә чаклы полковник Гайфетдинов Төньяк-Көнбатыш фронтта 91 нче укрепрайон белән командалык итә. Бу дәвер эчендә аның гаскәрләре дошманның 57 һөҗүмен кире кагалар. 1943 нче елның җәендә һөҗүмгә күчкәч, 48 торак пунктны азат итәләр. Демьян операциясе тәгәлләнгәч, 91 нче укрепрайон Ставка резервына Мәскәү янына күчерелә. 1944 нче елның декабрендә Көнчыгыш Пруссиядә сугышлар алып баручы 50 нче армия составына җибәрелә. 1945 нче елның апрелендә Кенигсберг шәһәрен алу ул катнашкан соңгы зур хәрби операция була.

Сугыш тәгәлләнгәч тә полковник Сәетгәрәй Гайфетдинов Көнчыгыш Пруссиядә хезмәт итә. 1945 нче елның 11 нче июлендә аңа генерал-майор дәрәҗәсе бирелә. 1946 нчы елның августыннан алып, гомеренең ахырына чаклы М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академиясендә укыта. 1953 нче елның беренче февралендә вафат була. Кадере – Мәскәү шәһәренең Введение зиратында.

Хәрби хезмәтләре өчен Сәетгәрәй Гайфетдинов **“Ленин”, 4 тапкыр “Кызыл Байрак”, Польшаның “Грюнвальд тәресе” орденнары** һәм күпсанлы медальләр белән бүләкләнә.

***Рафик Насыйров, тарих укытучысы, тарих фәннәре кандидаты***

## Урам тренажерлары балаларга тапшырылды

**/Безнең спорт/**

Гәзитнең алдагы саннарында хәбәр ителгәнчә, безнең мәктәп үзган ел РИТЭК акционерлык җәмгыятенең социаль-мәдәни проектлар конкурсында катнашып, 200000 сумлык грант откан иде. Ул акчага мәктәпнең спорт мәйданчыгы өчен **урам тренажерлары** алынды. Май бәйрәмнәре арасындагы ял көннәрендә әлеге җиһазлар мәйданчыкка урнаштырылды. Тренажерлар өстенә яңгыр явып тормасын өчен махсус түбә дә корылды. Хәзер инде укучылар өчен саф һавада яздан көзгә чаклы актив спорт белән шөгыльләнү мөмкинлеге күпкә артты.



## Безнекеләр – беренче!

15 нче май көнне Чистай шәһәрендә үзган татарча көрәш буенча ярышта **Илһам Камалов** шәкертләре 5 призлы урын яулап кайттылар. **Илдус Камалов** 55 һәм 70 кг авырлыкта ике беренче урынга ия булды. **Ильяс Хәбибрахманов** 60 кг, **Халит Нурматов** 55 кг авырлыктагылар арасында беренче урыннарны алдылар. **Рияз Галимов** 50 кг авырлыкта өченче урынга лаек булды. Афәрин, егетләр!


Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина
Редколлегия әгъзалары:
Әминә Туктамышева, Сара Насыйрова
Виктория Нукина, Рузилә Мөхәммәтова
Зөлфирә Сафиуллина



# Мәктәп хәбәрчесе

**№5**
(№26)
май
2021 ел

Түбән Майна урта мәктәбе гәзите

Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru


## Туган тел турында уйланулар

**/Мөхәррир сүзе/**

Быелгы ел Туган телләр елы диеп игълан ителгәч, безнең мәктәптә бу юнәлештә шактый эшләр башкарылды. Мәктәп, район, республика чарасымы – бик теләп, бар көчебезне куеп катнашабыз. Шул ук вакытта туган телебезнең бүгенге хәле һәм киләчәк язмышы турыда уйланулар да көнделне борчып тора.

Тел дигән олы хәзинә турында яңа нәрсә әйтеп буламы икән? Читен эш. Ә әйтергә кирәк. Бүген әйтмәсәк, иртәгә соң булуы бар. Сүзнең атасы – акыл, анасы – тел, дигәннәр борынгылар. Телне хәзинә дигәнем белән килешәсездер, мөгаен. Далаларның киңлеге, тауларның биеклеге, йолдызларның яктылыгы булган кебек, телнең дә байлыгы исәпсез. Аның кыйммәтен бәяләп буламы икән? Милли яшәешнең төп сыйфаты булганлыгы өчен генә дә телнең әһәмияте чиксез дияр идем.



Җир йөзендә телләр бик күп. Төгәл санын әйтү дә кыен. Аларның кайберләрендә миллиардлаган, ә кайсыларында берничә йөз кеше генә сөйләшергә мөмкин. Шуңа да карамастан, һәр халык өчен үз Туган теле кадерле һәм якын. Берәр чит җирдә үз телеңдә сөйләшкән кешене очратсаң, шатлыгың эчеңә сыймый. Туган телнең якынлыгы менә шунда күренә дә инде. Алдагы буыннардан безгә мирас итеп тапшырылган тел, кадерле ядкәр булып, хәзерге чорга кадәр килеп җиткән. Әби-бабаларыбыз күпме сугыш, чукындырулар, зинданнарда ябылулар күрсә дә, саклаган бит. Ә бүген, матди тормышыбыз нинди алдынгы булуга карамастан, гасырлар төбеннән үрелеп үскән Татар телебез сират күперен кичә. Аны без сакламасак, куллану даирәсен киңәйтеп, балаларыбызга мирас итеп калдыра алмасак, ана сөтебез бәхилләнерме икән?

Бүгенге көндәге күңелләрне әрнеткән иң оятлы күренешләрнең берсе – ата-аналары татар булган балалар үзара рус телендә аңлашуы. Үзебезнең ана телебез дә искиткеч бай бит, югыйсә. Моңга (хәтта рус телендә тәрҗемәсе дә юк), көйгә салынган татар теле бүген бәясез кебек алар өчен. Борынгылар бит татарга тылмач кирәк түгел диеп бушка гына әйтмәгән. Татар теленә ия булу дөньядагы йөзләрчә миллион сандагы төрки халыклар белән иркеле аралашу мөмкинлеген ача. Башка бик күп телләр белеп тә, үз ана телеңне югалтсаң, милләтсез калачаксың. Кешенең тәнен, җанын туган тел сугарып килә. Ана телең холкыңны да билгели, аңыңа чиксез мөмкинлекләр бирә, алга үсәргә дәрт өсти. Тел үзенең вазифасын шул чакта башкара алачак, әгәр аның белән гади кешедән алып дәүләт башлыгына кадәр аралашса. Уку йортлары да дәүләт телләре дип аталган телләр белән исәпләшсә.

Сүземнең ахырында язучы Нурихан Фәттахның язып калдырган юлларын китерергә булдым. “Әгәр тиздән минем телем бетә икән, озакламый тамырым корый икән, бу дөньяда ник яшәргә дә, ник яратырга, балалар тәрбияләргә, чәчәкләр үстерергә? Нигә җыр, китаплар язарга? Икенең берсе – йә тере килеш туфракка әйләнергә, йә көрәшергә! Мин көрәшергә булдым”. Җир йөзенә гәүдәбез сыйгач, телебезгә генә урын табылыр. Алдагы тормышыбызда Нурихан ага киңәшләрен тотып яшәсәк иде.

***Мөхәррир Фәнүзә Гафиятуллина***

## Сау бул, мәктәп!



**22 май – соңгы кыңгырау бәйрәме**

Балачакның моңсу хатирәсе
Җиз кыңгырау булып чыңлыйдыр.
Озатып калып мәктәп ишегеннән
Теләкләрен безгә юллыйдыр.

Китап, дәфтәр, каләм белән бергә
Мәктәпнең син иң төп ядкәре.
Күз алдына китереп булмас иде
Кыңгыраудан башка мәктәпне.

Әй, кыңгырау, мәктәп тормышында,
Үз эшеңне тегәл үтисең.
Яңгыравык тавыш белән чыңлап,
Белем үрләренә өндисең.

Тик нигәдер май азагы җиткәч,
Моңсулана җитди тавышың.
Сизәсеңме әллә, кыңгыравым,
Укучының китеп барышын.

*“Мәктәп хәбәрчесе”редколлегиясе*



## Хушлашыр чак җитте, дусларым

**/Мәктәп тормышы/**




**Соңгы кыңгырау бәйрәме** – уку елы дәвамында мәктәп өчен иң мөһим чара, чөнки үз канаты астында укыган укучыларын олы тормышка озата ул. Укытучы май ахырында уңыш җыя, чөнки укучыларның 11 ел укыган хезмәтләренең нәтиҗәсен күрү вакыты җитә. Шунлыктан, бу бәйрәм берук вакытта моңсу да, шатлыклы да була.

22 нче май иртәсендә бәйрәмчә бизәлгән һәм матур көйләр яңгырап торган мәктәп ишегалды түреннән иңнәренә ал тасмалар аскан чыгарылыш сыйныф укучылары урын алды. Быел XI сыйныфны 2 егет һәм 1 кыз тәмамлый. Алар һәрберсе тәртипле, уйлап эшли торган укучылар. Мәктәптә уку дәверендә укытучылары һәм әти-әниләренә алар өчен кызарырга туры килмәде. Иҗади яктан сәләтле егетләр – Илназ белән Илсаф – мәктәптәге бәйрәмнәрнең йөзек кашлары иде. Айсылу тыйнаклык, сабырлык үрнәге булды.

IX сыйныфны 8 укучы тәмамлады. Аларның кайберләре X сыйныфка калып, укуны үзебезнең мәктәптә дәвам итәчәк. Бу сыйныфта Камалов Илдус белән Хәбибрахманов Ильяс – чын батырлар. Күпме көрәш мәйданнарында билне бирмәгән, авылыбызга, мәктәбебезгә дан китергән егетләр. Кызлардан Сафиуллина Зөлфирә, Туктамышева Әминә, Нукина Виктория район, республика күләмендәге төрле олимпиада һәм конкурсларда күп тапкыр җиңүләр яулап укыдылар.

Бәйрәм барышында мәктәпне тәмамлаучы абый-апаларына алмашка килүче бакча төркеме балалары да чыгыш ясады. Нәни дусларыбыз бәйрәмгә тырышып әзерләнгәннәр. Аларның матур чыгышлары хушлашу хисеннән моңайган тамашачыларның күңелләрен күтәреп җибәрде.

Соңгы кыңгырау бәйрәменең иң хөрмәтле кунаклары – әлбәттә, әти-әниләр. Алар укытучыларга рәхмәтләрен белдереп, мәктәпне тәмамлаучы укучыларга изге теләкләрен җиткерделәр.

Бәйрәмнең ахыры саубуллашу вальсы булса да, мәктәпне тәмамлаган дусларыбыз белән хушлашасы килми. Аларны киләчәктәге шатлыкларын, зур җиңүләрен уртаклашыр өчен туган мәктәбебездә көтеп калабыз. Ата-аналар һәм укытучылар ярдәмен тою аларга алдагы тормыш сынауларында зур ышаныч бирәчәк, дип уйлыйм.

***Виктория Нукина, IX сыйныф укучысы***

## Барыбызга уртак бер җиңү

**/Безнең бәйрәмнәр/**



Еллар агымында нинди генә үзгәрешләр булмасын, халкыбыз өчен **9 нчы май – Җиңү көне** зур бәйрәм булып кала бирә. Арабызда сугыш ветераннары инде калмаса да, сугыш чоры хатирәләрен яңартучы бу бәйрәмнең әһәмияте югалмый. Минемчә, соңгы елларда Бөек Ватан сугышы тарихы белән кызыксыну еллар узган саен арта гына бара.

Бөек Җиңүнең 76 еллыгына багышланган бәйрәм чаралары безнең укучыларның 8 нче май көнне Такталы авылында һәйкәл ачылу тантанасында катнашулары белән башланып китте. Ә 9 нчы май көнне мәктәпнең барча халкы, авылдашлар һәм кайткан кунаклар Түбән Майнаның “Шәһитләр мәчете” каршына җыелды. Бәйрәм чарасы сугыш китергән кайгы-хәсрәтне дә, җиңү шатлыгын да ачык чагылдырды. Тамаша башында укучылар, сафларга тезелеп, һәйкәл алдыннан җырлап марш белән уздылар. Сугыштан кайтмаганнар рухына дога кылу һәм чыгышлардан соң, түбән сыйныф укучылары елдагыча җырлы-шигырьле тематик монтаж куйды. Балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр бик матур итеп “Торналар” биюен башкардылар. Бу чыгышлар бәйрәмдә катнашучы бер генә кешене дә битараф калдырмагандыр. Үлемсез полк сафы белән узу – Җиңү көненең иң дулкынландыргыч өлеше. Укучылар тотып чыккан сугыш кырларында ятып калган авылдашларның фотосурәтләреннән төбәлгән күз карашлары “Безне онытмагыз!” – дип аваз сала сыман.

Бәйрәм дәвамында сугыш елларындагы солдат киемен кигән егетләребез, ул заманның коралларын тотып, һәйкәл каршында сакта тордылар. Аларның шундый формадан йөрүе безгә сугыш вакытына кайткан кебек тәэсир итте. Быел безнең мәктәп сугыш чоры әйберләренә тагын да баеды. 2000 нче елда мәктәпне тәмамлап киткән Замалетдинов Рәмзис абый сугыш елларында кулланылган хәрби амуниция үрнәкләре бүләк итте. Бәйрәм ахырында директор Рафик абый аңа мәктәп исеменнән зур рәхмәт белдерде.

***Әминә Туктамышева, IX сыйныф укучысы***

## Мәктәптә балалар Сабан туе

**/Безнең бәйрәмнәр/**

29 нчы май көнне авыл клубы артындагы болынлыкта балаларны яклау көне һәм Ураза гаете уңаеннан балалар Сабан туе уздырылды. Мәктәп чарасы буларак әзерләнсә дә, бәйрәм башланганчы ук аның форматы шактый киң булачагы ачыкланды. Бәйрәмдә катнашырга үзебезнең район авылларыннан гына түгел, күршедәге Чистай һәм Норлат районнарыннан килгән укучылар да катнашты. Дәрәҗәле кунаклардан бәйрәм белән котларга район башлыгы Гыйльманов Камил Камал улы, мәгариф бүлеге җитәкчесе Зәйдуллина Рәмзия Салих кызы, “Аксубай” агрофирмасы җитәкчесе Габдуллин Әсхәт Касыйм улы килделәр.



Сабан туе азан әйтү белән башланып китте. Уку елын гел бишле билгеләренә тәмамлаган укучылар Гафиятуллин Фаил белән Закирова Ләйсән мәйдан өстенә бәйрәм байрагын күтәрделәр. Шуннан соң сүз мәктәп директоры Рафик абыйга бирелде. Ул районда милли мәгариф үсешенә зур өлеш керткәне өчен район башлыгы Камил абыйга истәлек бүләге тапшырды. Мәктәпнең рәхмәт хатлары бәйрәмне оештыруда ярдәм иткән районыбыз мөхтәсибе Равил хәзрәткә, Габдуллин Әсхәт абыйга, Хәйруллин Назыйф абыйга, Чистайда яшәүче якташыбыз Гүзәл апага да бирелде. Ел буе мәчеттә балаларга дин дәресләре укыткан пенсионер укытучы Сәкинә апа мәчетнең рәхмәт хатына һәм истәлекле бүләккә ия булды. Уку елы дәвамында фән олимпиадаларында, төрле конкурсларда һәм спорт ярышларында зур уңышларга ирешкән укучылар грамоталар белән бүләкләделәр.

Тантаналы керештән соң бәйрәмнең сәнгать өлеше Сабан туе бирнәсен җыю йоласы белән башланды. Укучыларның чыгышлары укытучылар Ләйсән һәм Рузилә апалар җитәкчелегендә бик зәвыклы әзерләнгән иде. Башка еллардан аермалы буларак, бәйрәмдә әби-бабаларыбызның кыр эшләре сәхнәләштереп күрсәтелде. Җир эшкәртү, тырмалау, чәчү, ашлыкны уру һәм суктыру эшләре борынгы эш кораллары кулланып бик оста башкарылды. Җыр-биюләр Сабан туе ярышлары белән бергә үрелеп барды. Балалар көянтә-чиләк белән су ташу, кашыкка йомырка куеп узышу, капчык киеп йөгерү, кул көрәше, шакмак ташу, бүләк кисеп алу, арканнан үрмәләү, капчык сугышлары кебек уеннарда катнашып бүләкләр алдылар.

Бәйрәмнең иң кызган чагында учакта пылау пешеп өлгерде. Зур самоварда чәй кайнап чыкты. Табаларда коймак, бәрәңге пәрәмәчләре тәмле исләр чыгарып чыжлады. Сабан туе сыйларыннан бәйрәмдә катнашучы һәркем авыз итә алды. Бу ризыкларны әзерләүдә пешекче Илсөяр һәм Айгөл апалар белән бергә пылау остасы Әнвәр абый да зур тырышлык куйды.

Сабан туеның иң мавыктыргыч һәм дулкынланып карый торган өлеше – әлбәттә инде, көрәш. Бил алышырга теләүчеләр шактый күп җыелганлыктан, мәктәпнең тренеры Камалов Ильһам абый аларны 5 авырлык категориясенә бүлеп чыгарды. Көрәшне Чистайдан һәм Норлаттан килгән тренерлар хөкем итте. Һәр төркемдә өч урын билгеләнеп, җиңүчеләргә кыйммәтле бүләкләр белән мәктәп грамоталары тапшырылды. Әмма төп бүләк булган тәкәне иң көчле, иң тырыш егет кенә алачак. Кызу көрәш нәтиҗәсендә Сабан туе батыры исемен IX сыйныф укучысы Хәбибрахманов Ильяс яулады.

Бәйрәм балаларга гаеп бүләкләре тапшыру һәм кумәкләшеп “Туган тел” җырын җырлау белән тәгәлләнде. Көн болытлы, һәм ара-тирә яңгыр яугалап алуга карамастан, бәйрәмнән һәркем күтәренке кәеф белән, күңелләрендә халкыбыз йолаларына карата горурлык хисе алып кайтты. Авылыбызны шундый күркәм чара белән шатландырган өчен, бәйрәмнең төп оештыручысы мәктәп директоры Насыйров Рафик абыйга, әзерләүдә һәм уздыруда катнашкан мәктәп хезмәткәрләренә, чыгымнарның күпчелек өлешен каплаган мәчеткә йөрүче абыйларга барча балалар исеменнән олы рәхмәтебезне белдерәбез.

***Зөлфирә Сафиуллина, IX сыйныф укучысы***




**/Котлыйбыз!/**

Ямьле май аенда туган көн бәйрәмнәрен билгеләп үтүче укучыларыбыз V сыйныфтан **Шичкин Алины**, IX сыйныфтан **Туктамышева Әминә** белән **Хәбибрахманов Ильясны** чын күңелдән котлыйбыз. Аларга ныклы сәламәтлек, укуларында уңышлар, хыялларының тормышка ашуларын теләп калабыз.

Башлангыч сыйныф укытучысы һәм тәрбия эшләре буенча директор урынбасары **Хәйруллина Рузилә апаны** да гомер бәйрәме белән котлыйбыз.Тормышында һәм эшләрендә зур уңышларга ирешүен, ныклы сәламәтлек телибез.